ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 26.01.2026 79 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында урнашкан капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының һәм аларга якын территорияләрнең тышкы күренешен тикшереп тору мәсьәләләре буенча комиссия төзү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелешенә карата таләпләрен һәм капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүне раслау турында» 2023 елның 29 маендагы 857 номерлы карары, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр Советының «Алабуга шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 16 октябрендәге 108 номерлы карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында урнашкан капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының, шулай ук аларга якын территорияләрнең тышкы күренешен тикшереп тору максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында урнашкан капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының һәм аларга якын территорияләрнең тышкы күренешен тикшереп тору мәсьәләләре буенча комиссия төзергә.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында урнашкан капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының һәм аларга якын территорияләрнең тышкы күренешен тикшереп тору мәсьәләләре буенча комиссия эше турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 00E09CCE890C334E03E097153C40025FA0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 13.01.2026 до 08.04.2027

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
20__елның “__” ________
______________номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында урнашкан капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының һәм аларга якын территорияләрнең тышкы күренешен тикшереп тору мәсьәләләре буенча комиссия эше турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында урнашкан капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының һәм аларга якын территорияләрнең тышкы күренешен тикшереп тору мәсьәләләре буенча комиссия, капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларын, шулай ук аларга якын урнашкан, торышы канәгатьләнерлек булмаган территорияләрне тиешле хәлгә китерү максатларында төзелә.

1.2. Комиссия — Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә хисап тотучы даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.3. Комиссия составы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта).

1.4. Үз эшчәнлеге барышында Комиссия:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы;

Россия Федерациясе Торак кодексы;

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелешенә карата таләпләрен һәм капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүне раслау турында» карары;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы;

Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр Советының «Алабуга шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 16 октябрендәге 108 номерлы карарына таяна.

## 2. Комиссия эшчәнлегенең төп юнәлешләре

2.1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелешенә карата таләпләрен һәм капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүне раслау турында» 2023 елның 29 маендагы 857 номерлы карары, Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр Советының «Алабуга шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 16 октябрендәге 108 номерлы карарында каралган капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының һәм аларга якын территорияләрнең тышкы күренеше таләпләргә туры килмәгән очракта ачыкланган мәсьәләләргә карата чаралар күрү.

2.2. Күчемсез милек объекты хокук ияләрен ачыклау, хокук бозуларны бетерү ысулын билгеләү.

2.3. Капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының хокук ияләре белән аларны тиешле хәлгә китерү максатында үзара хезмәттәшлек итү.

2.4. Төзекләндерү эшләрен гамәлгә ашыру һәм билгеләнгән срокларны үтәүне контрольдә тоту.

2.5. Комиссия компетенциясенә керә торган башка мәсьәләләрне аның эшчәнлеге юнәлешләре нигезендә карау.

## 3. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары

**3.1. Бурычлары:**

3.1.1. Комиссиягә кергән Алабуга муниципаль районының уңайлы шәһәр мохитен һәм тышкы күренешен булдыруга бәйле беркетмәләрне, гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне һәм башка документларны карау;

3.1.2. Комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү;

**3.2. Хокуклары:**

3.2.1. Карала торган мәсьәләләр буенча Алабуга муниципаль районының структур бүлекчәләреннән һәм башка оешмалардан мәгълүмат, белешмәләр, өземтәләр, аңлатмалар соратып алу;

кирәк булганда аларның вәкилләрен комиссия утырышларына чакыру;

3.2.2. Тикшерү актын төзү, капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларын тикшерү юлы белән Алабуга муниципаль районы территориясен мониторинглауны гамәлгә ашыру (2 нче кушымта);

3.2.3. Хокук ияләренең үз объектларын тиешле хәлгә китерү эшләрен башкару барышын һәм аларның срокларын үтәвен тикшереп тору.

3.2.4. Алабуга муниципаль районының структур бүлекчәләре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча территориаль бүлекләре, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы Алабуга районы буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының төп идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре идарәсе һәм кирәк булганда башка дәүләт учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлек итү;

3.2.5. Комиссия эшчәнлеге юнәлешләрендә каралган башка гамәлләрне башкару.

## 4. Комиссия эшчәнлеген оештыру

4.1. Комиссия эшчәнлеге белән комиссия рәисе идарә итә, ә ул булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары. Комиссия үз эшен әлеге Нигезләмә нигезендә, ирекле һәм ачык рәвештә аның компетенциясенә кергән мәсьәләләрне тикшереп алып бара.

4.2. **Комиссия составы:**

комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре, комиссия әгъзалары;

4.3. **Комиссия рәисе:**

Материалларны һәм документларны алдан карау тәртибен билгели һәм оештыра;

Комиссия утырышларын үткәрә һәм аларда рәислек итә;

Комиссия исеменнән җибәрелә торган хатлар, мөрәҗәгатьләр, актлар, беркетмәләр һәм башка документларны имзалый;

Әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне башкара.

4.4. **Комиссия рәисе урынбасары**:

Комиссия эшен оештыра;

Көн тәртибе проектын формалаштыра һәм утырышларны әзерләүне җитәкли;

Комиссия рәисе вазифаларын ул булмаганда башкара;

4.5. **Комиссия секретаре:**

Гаризаларны, хәбәрләрне, тәкъдимнәрне һәм башка кергән документларны кабул итә һәм терки;

Комиссия тарафыннан каралачак мәсьәләләр өчен материаллар әзерли;

Комиссия утырышын оештыра;

Комиссия әгъзаларына чираттагы утырышка материаллар җибәрә;

Утырышларның беркетмәсен алып бара һәм терки;

Объектларны (территорияләрне) тикшерү актларын төзи һәм терки;

Комиссия документларын алып бара;

Рәис кушуы буенча Алабуга муниципаль районы органнары, дәүләт һәм башка структуралар, шулай ук юридик һәм физик затлар белән эшлекле хат алыша.

4.6**. Комиссия әгъзалары**:

Комиссия эшендә катнаша;

Комиссиягә карау өчен тәкъдимнәр кертә, аларны әзерләүдә, фикер алышуда һәм карарлар кабул итүдә катнаша;

Комиссия йөкләмәләрен үти.

4.7. Комиссия карары буенча эшче төркемнәр төзелергә мөмкин.

Алар составына Алабуга муниципаль районы органнары вәкилләре һәм хәл ителә торган мәсьәләләргә бәйле рәвештә башка затлар керергә мөмкин.

Эшче төркемнәрнең максатлары һәм бурычлары аларны булдыру турында Комиссия карарлары белән билгеләнә.

## 5. Комиссиянең эш тәртибе

5.1. Комиссия эшенең төп рәвеше булып даими рәвештә, кимендә айга бер мәртәбә уздырыла торган утырышлар тора. Рәис яки рәис урынбасары карары буенча чираттан тыш утырышлар үткәрелергә мөмкин.

5.2. Утырышка материаллар комиссия әгъзаларына сәркатип тарафыннан утырыш көненнән өч эш көне кала алдан җибәрелә.

5.3. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының кимендә 2/3 өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия әгъзаларының утырышларда катнашуы мәҗбүри.

5.4. Комиссия карарлары Комиссиянең утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

5.5. Утырышның һәр акты беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырыш уздырылган көннән алып 5 эш көне эчендә утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана.

5.6. Утырыш беркетмәсе секретарь тарафыннан комиссиянең барлык әгъзаларына, ә беркетмәдән өземтәләр утырыш датасыннан алып 5 эш көне эчендә утырышта каралган объектларның хокук ияләренә җибәрелә.

5.7. Комиссия эшенә белгечләр, экспертлар, оешма вәкилләре комиссия рәисе белән килешенеп җәлеп ителергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында урнашкан капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының һәм аларга якын территорияләрнең тышкы күренешен тикшереп тору мәсьәләләре буенча комиссиясе эше турында Нигезләмәгә 1 нче кушымта
______ № _____

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында урнашкан капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының һәм аларга якын территорияләрнең тышкы күренешен тикшереп тору мәсьәләләре буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Комиссия составы | Вазифасы |
| Комиссия рәисе | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| (Комиссия рәисе урынбасары | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Комиссия секретаре: | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы |

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында урнашкан капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының һәм аларга якын территорияләрнең тышкы күренешен тикшереп тору мәсьәләләре буенча комиссиясе эше турындагы Нигезләмәгә 2 нче кушымта
______ № _____

**Объектны (территорияне) тикшерү акты № __**

Объектны тикшерү Алабуга муниципаль районында урнашкан капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларының һәм аларга якын территорияләрнең тышкы кыяфәтен контрольдә тоту мәсьәләләре буенча комиссия тарафыннан үткәрелде:

_____________________.
(вазифасы, комиссия әгъзасының яки әгъзаларының исем-фамилиясе, тикшерү үткәргәннәр)

Тикшерүне үткәрү чоры: ________________________.

Тикшерү үткәрү нигезе: ________________________.

Тикшерү һәм мәгълүматларны өйрәнү нәтиҗәсендә түбәндәгеләр ачыкланды:

1. Объект (территория) исеме: ____________________.
2. Объект (территория) урнашкан урынның адресы: __________________.
3. Объект (территория) хуҗасы: ____________________________.
4. Объектның (территориянең) функциональ билгеләнеше: _______________.
5. Кыскача характеристика (объектта (территориядә) урнашкан биналар, корылмалар һәм бүлмәләр тасвирламасы белән): ____________________.
6. Тирә-як территорияләренең, объектларның тасвирламасы: __________________.

Объектны (территорияны) тикшерүче затның (затларның) нәтиҗәләре һәм тәкъдимнәре:

Объектны (территорияне) тикшерүне үткәргән зат(лар),
кирәк дип саный(лар) түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру: _______________.

______ елның «___»_______________ _

Имзалар: __________/_________________
(җитәкче вазифасы (имза) (имзаның аңлатмасы)

Лист согласования к документу № 79 от 26.01.2026
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 29.01.2026 09:08

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 29.01.2026 - 10:38 | - |